**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

23.09.2016

№ 542

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Инновацион кластерлар – дөньякүләм дәрәҗәдә инвестицияләр җәлеп итү лидерларын үстерү» Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының өстенлекле проекты турында» 2016 елның 27 июнендәге 400 номерлы карары нигезендә эшләнгән һәм 2016 елның 8 июлендә статс-секретарь – Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министры урынбасары О.В. Фомичев белән килештерелгән инновацион кластерлар – Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Инновацион кластерлар – дөньякүләм дәрәҗәдә инвестицияләр җәлеп итү лидерларын үстерү» өстенлекле проектында катнашучылар исемлегенә кертүгә заявкаларны сайлауга конкурс уздыру тәртибе нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгын Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Инновацион кластерлар – дөньякүләм дәрәҗәдә инвестицияләр җәлеп итү лидерларын үстерү» өстенлекле проектын гамәлгә ашыруда Кама инновация территориаль-җитештерү кластеры (алга таба – Кама кластеры) катнашу мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы белән хезмәттәшлекне тормышка ашыруда Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы вәкиле итеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы икътисад министры Здунов Артем Алексеевичны Татарстан Республикасы исеменнән Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Инновацион кластерлар – дөньякүләм дәрәҗәдә инвестицияләр җәлеп итү лидерларын үстерү» өстенлекле проектын гамәлгә ашыруга Кама кластерын кертү турында хатка (заявкага), шулай ук әлеге боерык нигезендә бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру белән бәйле документларга кул кую вәкаләте бирергә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ
БҮЛЕК
ОБЩИЙ
ОТДЕЛ